СОВЕТ УСАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4 с.Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УСАЛИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Беренче май ур., 4 нче йорт, Усали авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

т тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение                    Карар

**№ 3-24**                    **от 13.06.2023г.**

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге Советының 2015 елның 29 апрелендәге 6-44 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында” 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында” Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында” Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында"2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы федераль законнар, “Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге Советының 2015 елның 29 апрелендәге “Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында интернет челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеген раслау турында" 6-44 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемендә, 1 пунктта һәм 1 нче кушымтада "в сети "Интернет" челтәрендә” сүзләрен " рәсми сайтларда" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Үсәли авыл җирлеге
Советы рәисе /Зиатдинов А.И./